# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Чүпрәле муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Чүпрәле муниципаль районы составына керүче "Звезда авыл җирлеге" һәм "Үби авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**


"Чүпрәле муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 12 (V өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Чүпрәле муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Чүпрәле муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## <u>карта-схемасы</u>




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
- <sub></sub>10 - тоташу ноктасының тәртип саны
- <u>10</u> - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 25(10)-26(12) | - Чуаш Республикасы |
| 26(12)-27(13) | - Ульяновск өлкәсе |
| 27(13)-33(6) | - Чуаш Республикасы |
| 33(6)-37(5) | - Буа муниципаль районы |
| 37(5)-25(10) | - Ульяновск өлкәсе |

"Чүпрәле муниципаль районы" муниципаль берәмлеге
составына керүче авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Алешкин-Саплык авыл җирлеге |
| 2 | Зур Аксу авыл җирлеге |
| 3 | Зур Чынлы авыл җирлеге |
| 4 | Городище авыл җирлеге |
| 5 | Звезда авыл җирлеге |
| 6 | Кече Чынлы авыл җирлеге |
| 7 | Марс авыл җирлеге |
| 8 | Матак авыл җирлеге |
| 9 | Түбән Чәке авыл җирлеге |
| 10 | Яңа Борындык авыл җирлеге |
| 11 | Яңа Әлмәле авыл җирлеге |
| 12 | Яңа Ишле авыл җирлеге |
| 13 | Үби авыл җирлеге |
| 14 | Иске Чүпрәле авыл җирлеге |
| 15 | Иске Кәкерле авыл җирлеге |
| 16 | Иске Чокалы авыл җирлеге |
| 17 | Иске Шәйморза авыл җирлеге |
| 18 | Чуаш Чүпрәлесе авыл җирлеге |
| 19 | Шланга авыл җирлеге"; |

2) 7 нче кушымтада:

а) дүртенче абзацта "Звезда, Үби авыл җирлекләре һәм Чуаш Республикасы чикләре тоташкан урында Татар Үбие авылыннан 1,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасына" сүзләрен "Звезда, Үби авыл җирлекләре һәм Чуаш Республикасы чикләре тоташкан урында Татар Үбие авылыннан 3,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 47 нче тоташу ноктасына" сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Звезда авыл җирлеге чиге Үби авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 47 нче тоташу ноктасыннан алып, инешне кисеп үтеп, 2,46 км көньяк-көнбатышка таба

авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 110 м төньяк-көнчыгышка таба, 990 м төньяк-көнбатышка таба инешкә кадәр, 840 м әлеге инеш буенча аның Кече Чынлы елгасына койган җиренә кадәр уза, алга таба бу елга буенча 6,0 км төньяк-көнбатышка таба Алешкин-Саплык, Звезда һәм Үби авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Шигали авылыннан 200 м төньякта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) сигезенче – унынчы абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 15 нче кушымтада:

а) унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Үби авыл җирлеге чиге Звезда авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Звезда, Үби авыл җирлекләре һәм Чуаш Республикасы чикләре тоташкан урында Татар Үбие авылыннан 3,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 47 нче тоташу ноктасыннан алып, инешне кисеп үтеп, 2,46 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 110 м төньяк-көнчыгышка таба, 990 м төньяк-көнбатышка таба инешкә кадәр, 840 м әлеге инеш буенча аның Кече Чынлы елгасына койган җиренә кадәр уза, алга таба бу елга буенча 6,0 км төньяк-көнбатышка таба 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

б) унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Үби авыл җирлеге чиге Чуаш Республикасы белән чиктәш җирдә 47 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 33 нче (6 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) уникенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты


Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 1 июле
№ 45-ТРЗ

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Чүпрәле муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

# Чүпрәле муниципаль районының «Звезда авыл җирлеге» һәм «Үби авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең чиктәш чиге участогы карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- район чиге
- җирлекләрнең чикләре
- Звезда авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Үби авыл җирлеге территориясе